ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2023 г. Заинск № 774

**2024 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп юнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлеше 11 пункты, «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күп юнәлешле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2024 елга расларга:
«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология,

хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп юнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга, кушымта итеп бирелә торган, норматив чыгымнарны;

балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп юнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,65 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «03» 10
774 номерлы карары
белән расланган.

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп юнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, бер укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җире | 7 851 | 14 539 | 17 447 |
| | авыл җире | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җире | 7 750 | 14 351 | 17 222 |
| | авыл җире | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | шәһәр җире | 8 155 | 15 101 | 18 121 |
| | авыл җире | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Эколого-биологик | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җире | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җире | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җире | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җире | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |